**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
# КАРАРЫ

Сарлы авылы №115-57 13 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-36 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 29 октябрендәге 12-3 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 56-30 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 91-46 номерлы карарлары басмасында) үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 маддәсенең 2 бүлегенә һәм 406 маддәсенең 1 бүлегенә туры китереп,

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-36 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 29 октябрендәге 12-3 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 56-30 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 91-46 номерлы карарлары басмасында), түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 нче бүлектә:

а) 2 бүлекчәне түбәндәге эчтәлектәге 4 нче абзац белән тулыландырырга: “квартираның өлеше”;

б) 3 нче бүлекчәне түбәндәге эчтәлектәге 5 нче абзац белән тулыландырырга: “торак йортларның өлешләре”.

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән бер ай узгач, үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затларның милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә: http://aznakayevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Шәрипов М.Р.